ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасы Сайлау кодексына үзгәрешләр кертү турында» 424-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты А.Г. Хәбибуллин тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы Сайлау кодексына үзгәрешләр кертү турында» 424-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2023 елның 8 июне
№ 1987-VI ДС

Проект

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутаты
А.Г. Хәбибуллин тарафыннан
кертелә

**«Татарстан Республикасы Сайлау кодексына үзгәрешләр кертү турында»**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

Татарстан Республикасы Сайлау кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 5, № 12 (I өлеш); 2010, № 6 (I өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш); 2013, № 10; 2014, № 5; 2015, № 5; 2016, № 4, № 6 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 27 (I өлеш), № 52 (I өлеш), № 55 (I өлеш); 2018, № 44 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 28 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 77 (I өлеш); 2023, № 11 (I өлеш), № 27 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 39 статьяның 7 өлешендә «кандидат дәвалана торган стационар дәвалау-профилактика учреждениесенең» сүзләрен «кандидат дәвалана торган стационар шартларда медицина ярдәме күрсәтүче медицина оешмасы» сүзләренә алмаштырырга;

2) 41 статьяның 4 өлешендә «кандидат дәвалана торган стационар дәвалау-профилактика учреждениесенең» сүзләрен «кандидат дәвалана торган стационар шартларда медицина ярдәме күрсәтүче медицина оешмасы» сүзләренә алмаштырырга;

3) 42 статьяның 3 өлешендә «кандидат дәвалана торган стационар дәвалау-профилактика учреждениесенең» сүзләрен «кандидат дәвалана торган стационар шартларда медицина ярдәме күрсәтүче медицина оешмасы» сүзләренә алмаштырырга;

**2 статья**

Әлеге Заокн рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

«Татарстан Республикасы Сайлау кодексына үзгәрешләр кертү турында»
Татарстан Республикасы законы проектына аңлатма

«Татарстан Республикасы Сайлау кодексына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проекты (алга таба – закон проекты) Татарстан Республикасы законнарын федераль законнарга туры китерү максатында эшләнде.

Закон проекты Татарстан Республикасы Сайлау кодексында кулланыла торган терминологияне «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законда һәм «Россия Федерациясендә гражданнарның сәламәтлеген саклау нигезләре турында» 2011 елның 21 ноябрендәге 323-ФЗ номерлы Федераль законда кулланыла торган төшенчәләр нигезендә төгәлләштерүгә юнәлдерелгән.

Шушы максатта закон проектында Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 39 статьясындагы 7 өлешендә, 41 статьясындагы 4 өлешендә һәм 42 статьясындагы 3 өлешендә кулланыла торган «стационар дәвалау-профилактика учреждениесенең» сүзләрен « стационар шартларда медицина ярдәме күрсәтүче медицина оешмасы» сүзләренә алмаштырырга тәкъдим ителә.

**«Татарстан Республикасы Сайлау кодексына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы кабул ителүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалтуы танылырга, туктатып торылырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасы Сайлау кодексына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы закон актларының үз көчләрен югалтуын тануны, туктатып торуны, үзгәртүне яисә кабул итүне таләп итми.

**«Татарстан Республикасы Сайлау кодексына үзгәрешләр кертү турында»**
**Татарстан Республикасы законы проектын**
**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Татарстан Республикасы Сайлау кодексына үзгәрешләр турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итми.